СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 11-39 от «30» июня 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 1нче июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 6-8 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Мамадыш районы прокурорының 2020 елның 19 июнендәге 02-08-02-2020 нче протесты нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 1нче июлендәге 6-8 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлеге 11 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планлаштырылган тикшерүне еллык план буенча тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү өчен түбәндәгеләрдән соң бер ел узгач нигез булып тора:

1) Дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәрнамәгә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;

1.1) социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның

000034

муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган Социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;

3) коммуналь ресурсларны һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү).».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов